***Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлил 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә.***

*1913* ***елда Мусаның әтисе Мостафа абзый, ишле гаиләсен ияртеп, Оренбург шәһәренә күчә һәм вак-төяк сату эшләре белән шөгыльләнә башлый. 1918 елны ул туган авылына кире кайта һәм бер елдан шунда вафат була.***




**Муса алты яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсә елларында (1914—1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев иҗатлары белән яыннан таныша, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кулъязма журналга урнаштыра бара.**

# 1919 ЕЛНЫҢ ОКТЯБРЕНДӘ, ОРЕНБУРГ ШӘҺӘРЕ ДУТОВ ГАСКӘРЛӘРЕ ТАРАФЫННАН КАМАП АЛЫНГАН ЧОРДА, ТӨРКСТАН ФРОНТЫ ПОЛИТИДАРӘСЕ ОРГАНЫ «КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ» ГАЗЕТАСЫНДА УНӨЧ ЯШЬЛЕК М. ҖӘЛИЛНЕҢ «БӘХЕТ» ИСЕМЛЕ ШИГЫРЕ БАСЫЛЫП ЧЫГА.

*Шуннан соң анның революция, көрәш рухы белән сугарылган романтик шигырьләре матбугат битләрендә еш күренә башлый.*








***1922 елның көзендә М. Җәлил Казанга килә. Башта ул «Татарстан» газетасы редакциясендә эшли, ә 1923 елдан Татрабфакта укый башлый.1933—1934 елларда М. Җәлил Мәскәүдә «Коммунист» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли.***

**1934 ЕЛДА ШАГЫЙРЬНЕҢ КҮП КЕНӘ ШИГЫРЬЛӘРЕН ЭЧЕНӘ АЛГАН ШАКТЫЙ ЗУР ҖЫЕНТЫГЫ («ОРДЕНЛЫ МИЛЛИОННАР») БАСЫЛА ҺӘМ ШУЛ УК ЕЛНЫ «СТИХИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ» ИСЕМЕ БЕЛӘН САЙЛАНМА ШИГЫРЬЛӘРЕ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ РУС ТЕЛЕНДӘ ЧЫГА.**

,
А

ЛЕ





Муса Җәлил хөкем алдыннан.(1944г.)

ЛГӘ

РШЫ
ӘП,

1956 ЕЛНЫҢ 2 ФЕВРАЛЕНДӘ СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ БЕЛӘН МУСА ҖӘЛИЛГӘ ВАТАН СУГЫШЫ ЧОРЫНДА КҮРСӘТКӘН ТИҢДӘШСЕЗ НЫКЛЫГЫ ҺӘМ БАТЫРЛЫГЫ ӨЧЕН СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ИСЕМЕ БИРЕЛДЕ,



***ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты — бөтен дөньяга мәшһүр «Моабит дәфтәрләре» Ленин премиясенә лаек булды.***





М.ҖӘЛИЛ КЫЗЫ
ЧУЛПАН БЕЛӘН



# МЛЕ

66).


АХМЕТ ИСХАК
ПОЭТ-ГЕРОЙ
МУСА ДЖАЛИЛЬ

МУСА ДЖАЛИЛЬ
ВОЛЬНЫЕ ВЕТРЫ

МУСА ДЖАЛИЛЬ
МОИ ПЕСНИ

МУСА ДЖАЛИЛЬ

МУСА ДЖАЛИЛЬ
КРАСНАЯ РОМАШКА

# «БҮРЕЛӘР»



# БҮРЕЛӘР

КЕШЕЛӘР СУГЫША, КАН КОЯ,
КИСЕЛӘ МЕҢНӘРЧӘ ГОМЕРЛӘР.
ТӨН БУЕ УЛАШЫП ЯКЫНДА
ИСНӘНЕП ЙӨРИЛӘР БҮРЕЛӘР.
КҮПМЕ КАН, КҮПМЕ ЯШЬ АТ ИТЕ
ЯЛТЫРЫЙ БҮРЕНЕҢ КҮЗЛӘРЕ.
БИТ МОНЫ ТӨН БУЕ АТЫШЫП,
ТУРАГАН КЕШЕЛӘР ҮЗЛӘРЕ.

БҮРЕЛӘР БАШЛЫГЫ КАРТ БҮРЕ,
ИСЕРЕП КЕШЕЛӘР КАНЫНА
ЙӨРГӘНДӘ, СИСКӘНЕП
ТУКТАДЫ
БЕР АВЫР ЯРАЛЫ ЯНЫНА.
ЯРАЛЫ ЫҢРАША, САТАША,
КАЕНГА ТЕРӘГӘН БАШКАЕН.
КЫЗГАНЫП ЕГЕТНЕ, ҖИЛ
БЕЛӘН
ТИБРӘНЕП СЫКРАНА АК КАЕН.

КЫЗГАНЫП ЕГЕТНЕ, ЕЛЫЙЛАР
МИЛӘҮШӘ ҺӘМ ЛАЛӘ ЧӘЧӘГЕ.
ТӘГӘРИ ҮЛӘНГӘ, ЧЫК ТҮГЕЛ,
ГӨЛЛӘРНЕҢ ГӨНАҺСЫЗ ЯШЬЛӘРЕ.
КАРТ БҮРЕ ЕГЕТНЕ ИСНӘДЕ,
АПТЫРАП КҮЗЕНӘ КАРАДЫ.
ҺӘМ КИНӘТ НИДӘНДЕР СИСКӘНЕП,
БЕР ЧИТКӘ ТАЙПЫЛДЫ ЯРАЛЫ.



ЯРАЛЫНЫҢ ЗӘГЫЙФЬ СУЛЫШЫ
БӘРЕЛДЕ БҮРЕНЕН БОРНЫНА.
ЮК, БҮРЕ ТИМӘДЕ, САК КЫНА
БОРЫЛЫП ЮНӘЛДЕ ЮЛЫНА.
ТАҢ БЕЛӘН КИЛДЕЛӘР
КЕШЕЛӘР,
КҮРДЕЛӘР ЯРАЛЫ ЕГЕТНЕ.
ЯРТЫЛАШ УЛ ТАЙГАН ИСЕННӘН,
ШУЛАЙ ДА ЯШӘВЕ ӨМИТЛЕ.

КЕШЕЛӘР ЕГЕТНЕҢ ТӘНЕНӘ
КЫЗДЫРЫП ШОМПОЛЛАР
БАСТЫЛАР.
ТУЙГАНЧЫ ҖӘФАЛАП,
СОҢЫННАН
ЯЛГЫЗ АК КАЕНГА АСТЫЛАР.
КЕШЕЛӘР СУГЫША, КАН КОЯ.
КИСЕЛӘ МЕҢНӘРЧӘ ГОМЕРЛӘР.
ТӨН БУЕ УЛАШЫП ЯКЫНДА
ИСНӘНЕП ЙӨРИЛӘР БҮРЕЛӘР.
БҮРЕЛӘР, АҺ... ЛӘКИН БҮРЕЛӘР
БУ КАДӘР ҮК ЕРТКЫЧ ТҮГЕЛЛӘР.

